ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 февраль 2017 ел № 667

Эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру өлкәсендә Башкарма комитетның аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2014 елның 8 маендагы 2668 номерлы карары (Башкарма комитетның 2015 елның 1 июнендәге 3409 номерлы, 2016 елның 31 мартындагы 1440 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган эчке муниципаль финанс контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибе турында нигезләмәгә, түбәндәге эчтәлектәге 19.1 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«19.1. Контроль объектын тикшерә торган чор – агымдагы чор (ай, квартал, ел) һәм (яки) агымдагы елдан алдагы ел.».

2. Башкарма комитетның 2014 елның 29 декабрендәге 8283 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 1 июнендәге 3409 номерлы, 2016 елның 31 мартындагы 1440 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруның административ регламентының 22 пунктына, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) бишенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

2) түбәндәге эчтәлектәге утыз икенче абзац өстәргә:

«Контроль объектын тикшерә торган чор – агымдагы чор (ай, квартал, ел) һәм (яки) агымдагы елдан алдагы ел.».

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы Ә.А. Галиәкбәровага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин